Салям (МИР)

**Подписывайтесь
на газету «Салям»
на первое полугодие
2017 года
Цена - 166 рублей**
На ноябрь - декабрь 2016 г.
цена подписки - **56 рублей.**
Индекс газеты - **52381**
Можно подписаться
в редакции газеты «Салям».
Обращаться к Миляуше
**8-937-207-08-88**

Салям (МИР)

«Сәлам» гәҗитәсенә
2017 елның
беренче яртысына
язылырга онытмагыз,
кадерле
укучыларыбыз!
Бәясе - 166 сум

Салям (МИР)

Савап
аласыгыз
килсә

«Сәлам» гәҗитәсе
Коръән сүзләрен,
Пәйгамбәребез
Мөхәммәд Мостафа
салләллаһу галәйһи
үә сәлләм әйткән сүзләрне
халыкка җиткереп яши.
Бу «дәгъват» дип атала.
Ә дәгъват - олуг
савапларның берсе.
Шул савапка
ия буласыгыз килсә,
**«Сәлам» гәҗитәсен
үзегезгә дә яздырыгыз,
шулай ук
туганнарыгызга,
дус-ишләрегезгә,
таныш-белешләрегезгә
яздырып та
бүләк итегез.**

**Шулай ук
2016 елның ноябрь -
декабрь айларына**
язылу **бәясе - 56 сум.**
Исегезгә төшерәбез - язылу
һәр айның **20нә кадәр бара!**
Гәҗитәнең индексы - **52381**
Редакциягә килеп,
Миләүшәдә дә яздыра аласыз
**(8-937=207-08-88).**

Салям (МИР)

Мәгълүматны
**Миләүшә ГАЗЫЙМ**
туплады.

**Белем офыгыбыз**

# Язмыш һәм тормыш

**Татар телендә бик еш кулланыла торган "китап" сүзе гарәп теленнән алынма сүз булып тора, һәм ул татарчага "язма" дип тәрҗемә ителә. Ике телдә дә бер үк мәгънәне аңлаткан бу сүзләрнең ясалу ысулы да бертөрле.**

"Язма" сүзе татар телендәге "язу" фигыленә исем ясагыч кушымча өстәлеп барлыкка килсә, "китап" сүзе гарәп телендәге "кәтәбә" (язу) фигыленә исем ясагыч кушымча өстәлеп барлыкка килә.

Ә инде "китап", "язма" сүзләренең мәгънәсе һәркемгә дә аңлашыла - нинди дә булса информацияне билгеле бер символлар ярдәмендә озак саклана торган өслеккә сызып-язып кую.

Элегрәк, сүзләр озак саклансын өчен, ташка, киптергән балчык такталарга, агач кайрысына, кипкән тиреләргә чокып-сызгалап язып куйсалар, соңрак кәгазь битләргә буяу белән язып куя, зур станокларда шрифт белән бастыра башлыйлар. Шулай итеп, хәзер без аңлый торган китаплар, язмалар барлыкка килә.

Ләкин соңгы фәнни ачышлар нәтиҗәсендә, без хәзер информацияне элекеге вакытларда билгеле булмаган ысулар ярдәмендә дә саклап булганын аңлый алабыз. Бу ысулларга мисал итеп бер яктан, компьютер дискларында саклана торган цифрлы кодлар ярдәмендә язылган информацияне китереп үтсәк, икенче яктан ДНК күзәнәкләрендә саклана торган, билгеле бер химик молекулалар коды ярдәмендә язылган информацияне мисал итеп китереп үтәргә булыр иде.

Димәк, китаплар, ташка чокылып, яки кәгазь битләргә буяу белән генә түгел, ә нииндер кодлар ярдәмендә дә языла ала икән әле. Һәм мондый кодлар белән язылган "китап" информацияне, гади китапларга караганда, бик күпкә артыграк сыйдыра ала. Чөнки хәрефләре кечкенәрәк булган саен, бер үк китапка, зуррак хәрефләр белән язылганга караганда, күбрәк информация язарга була. Компьютер дискында хәрефләр зурлыгы берничә микроннарны тәшкил итсә, ДНК язмасындагы хәрефләр зурлыгы берничә атом күләме кадәр генә. Һәм әле бит атомнардан да кечкенәрәк хәрефләр белән язылган, безгә әлегә билгеле булмаган китапларның да бар икәнен теоретик яктан инкяр итеп булмый. Андый язмаларның да булуына ышаныч бар!

**Боз тавы (айсберг) су өстендә бик зур булып күренсә дә, әле аның су астындагы күзгә күренмәгән өлеше җиде мәртәбә артыграк икәнен истә тотып, безнең күзләребез күрә алган тормыштан җиде мәртәбә зуррак, күзләребезгә әле күренә алмаган тормышның да барлыгын онытырга ярамый.**

Күзгә күренә алган тормыш турында хәзерге заман фәне бик яхшы белсә, күзгә күренмәгән тормыш турында бары тик дин аркылы гына белеп була.

Шулай итеп, Ислам дине аркылы, без тормышның күзебезгә күренмәгән өлешендә, җиде кат күк өстендә саклануы Ачык Китапның барлыгын беләбез. Коръән сүрәләрендә ул Китап турында берничә төрле исем белән әйтеп үтелә:

Ачык Китап,
Саклаучы Китап,
Саклануы Китап,
Ана Китап,
Әҗәл Китбы,
әл-Ләүһ әл-Мәхфуз (Такта Саклаучы),
Хөрмәтле Язма,
Ачык Кулланма.

Һәм кайбер риваятьләрдә әйтелгәнчә:

"Ул Китапның озынлыгы күк белән җир арасы сыман, киңлеге көнчыгыш белән көнбатыш арасы кебектер".

Әнә шундый гаять зур Китапта дөньядагы булган бөтен әйберләр турында ачык итеп язып куелган.

**"Нәмел" сүрәсенең 75нче аятендә:** "...һәм күкләрдә дә, җирдә дә Ачык Китапта булмаган яшерен бер нәрсә дә юк!" - дип әйтелә.

Күзләребезгә күренә алмаган Китапның, татар телендә әйтсәк - Йазманың, нинди икәнен аңлатыр өчен, Аллаһы Тәгалә ул заманнарда яшәгән кешеләргә аңлашыла торган сүзләрне куллана.

Шулай итеп, "такта", "төргәкләр", буяу белән языла торган "китап" сүзләре ярдәмендә, кешеләр җиде кат күктә саклануы Йазманың нинди икәнлеге турында белеп алалар. Ләкин хәзерге вакытта без ул Йазма турында тагын да тирәнрәк аңлый алабыз.

Йазма турында тирәнрәк аңлый башлаганны, иң элек ни өчен "Язма" дип түгел, ә "я" хәрефе урынына "йа" хәрефләрен кулланылганына тукталып үтик.

**Беренчедән**, "я" хәрефе татар теленә урыс кириллицасыннан үтеп керә, һәм ул хәреф белдергән авазның татарча дөресрәк язылышы - "йа" хәрефләре аркылы булыр иде.

**Икенчедән**, киләчәктә без "й" һәм "а" хәрефләре белдергән авазларның бик мөһим әчтәлек алып килгәннәре турында беләчәкбез.

Һәм татар сүзләрендәге бөтен "я", "ю", "е" хәрефләрен "й" хәрефе аркылы яза башларбыз, дип ышанам. Ә хәзергә кешеләргә аңлаешлырак булсын өчен, бары тик "Йазма" сүзендә генә "й" хәрефе кулланып, ул хәреф белдергән авазның мөһим икәнлегенә тагын бер кат басым ясап үтәсе килә. Миллиардлаган галактикалар белән тулган галәмне вакуум бушлыгы чорнап алган. Космостагы вакуум бушлыгы - кеше аңлый алырлык иң соңгы чик.

**Менә шул бушлыктан соңгы бушлыкта (чөнки кешеләр бу ике бушлыкны да күрә алмый) кешеләр күзенә күренә алмаслык ысул белән язылган «Йазма» саклана да инде.**

Һәм ул Йазманың сүзләре буяу белән кәгазьгә түгел, ә хәзерге заманда кешеләр аңлый алган иң кечкенә кисәкчекләр - кваркләрдан да кечкенәрәк булган ясселыкта, билгеле бер код белән язылган булуы фәнни яктан исбатланган белемгә якынрак тора.

**Ислам динендәге Олугъ Китап хакында, ул буяу белән түгел, ә код белән язылган дип әйтү, бу - Ислам диненә яңалык кертү түгел. Бу - "кыяс", ягъни "чагыштыру" аркылы хөкем итү дигән сүз.**

Без үзебезнең күзләребезгә күренә алмаган "гаиб" әйберләрне тормышта күрә алган әйберләр белән чагыштырып карап аңлыйбыз, Коръән һәм хәдисләргә таянып, кем чыгарган күк. Мисал өчен, һәрбер тере күзәнәктә була торган ДНК "китабын" Аллаһы Тәгалә буяу белән язып куймаган бит!

ДНКда саклануы информация билгеле бер атомнар коды аркылы язылган. Әгәр Аллаһы Тәгалә бер кечкенә генә күзәнәкнең яшәешен шулай код белән язып куйган икән, бөтен зур галәмнең барлыгын код белән язып кую тагын да әһәмиятлерәк. Чөнки шундый ысул белән язып кына информацияне бер урынга күп итеп тупларга, һәм ул информациянең туктаусыз хәрәкәткә әйләнеп торуын тәэмин итәргә мөмкин.

Бөтен галәм туктаусыз хәрәкәттә. Кечкенә генә элементар кисәкчекләрдән алып, иң зур галактикаларга кадәр булган бөтен барлык та бик зур тизлек белән яки сизелмәслек әкрен тизлек белән хәрәкәт итә.

Һәм бөтен хәрәкәтләрнең дә барлыкка килүе Ачык Китапта шул хәрәкәт турында Аллаһы Тәгаләнең "Бул!" дип язып куелган мәгънә төшенчәсенең тормышка ашуы белән бара.

Һәрбер хәрәкәтнең дә үз вакыты язылган, һәм төгәл итеп үз вакыты буенча бөтен хәрәкәтләр дә бер-бер артлы булып торалар. Шулай итеп, безнең Язмыш нигезендә безнең Тормыш барлыкка килә. Үз язмышыңны дөрес кабул итеп кенә, туры юлда булырга мөмкин.

**Галимҗан ГАЛИМҖАН.**

## Изге Китабыбыз Коръәни-Кәрим сүзе

**Гошер**

«Аллаһыдан нигъмәтләр алып,
саран булган кешеләр,
саранлыгыбыз үз файдабызга
дип уйламасыннар, киресенчә,
ул (саранлык) алар өчен
бик начар булып чыгачак.
Саранлыкларына күрә,
җыелган маллары
кыямәт көнендә аларның
муеннарына чорналачактыр.
Күкләрнең, җирнең мирасы -
Аллаһыныкыдыр.
Аллаһы сез кылганнардан
хәбәрдардер».
(«Әл-Гыймран» сүрәсенең
180 нче аяте)

**Изгелек белән...**

«Әй, тәрбияче Аллаһы!
Раббыгызга Иман китерегез!» -
дип Иманга чакыручыны ишеттек
һәм Иман китердек.
Әй, Раббыбыз!
Безнең гөнаһларыбызны кичер.
Безне бозык эшләребездән
сакла һәм изгеләр
белән бергә вафат ит!».
(«Әл-Гыймран» сүрәсенең
193 нче аяте)

**Ышанучыларны сөя**

«...Аллаһы Үзенә
тәвәккәлләгәннәрне сөя».
(«Әл-Гыймран» сүрәсенең
159 нчы аяте)

**Рөхсәтсез кермәгез**

«Үзегезнең өйләрегездән
башка өйләргә рөхсәт сорамыйча,
хуҗаларына сәлам
бирмичә кермәгез».
(«Нур» сүрәсенең
27 нче аяте)

**Пәйгамбәребез Аллаһы сүзен сөйли**

«Пәйгамбәр үзлегеннән сөйләми,
аның әйткән хәдисләре
Аллаһы Тәгалә тарафыннан
индерелгән,
йәгъни вахи».

**Хак динебезне ташласаң**

«Ий, мөэминнәр!
Әгәр сезнең арагыздан
берәү хак динен ташлап,
мөртәт булса,
Аллаһы алар урынына үзенә
сөекле һәм Аллаһыны сөюче
кавемне тиздән китерер.
Алар мөэминнәргә
йомшак күңелле,
кяферләргә каты
күңелле булырлар.
Алар Аллаһы юлында
Ислам динен куәтләр өчен
бөтен көчләрен куярлар».
(Әл-Мәидә» сүрәсенең
54 нче аяте)

**Мәетләр дога көтә**

Аллаһы Тәбарәкә үә Тәгалә
Коръәндә мәетләребез өчен
дога кылырга өйрәтә.
«...Раббыбыз, безне һәм
бездән элек килеп киткән
Иманлы кардәшләребезне,
зинһар, ярлыка.
Күңелләребездә
Иман китергәннәргә
каршы һичбер хосетлек калдырма.
Раббыбыз, шик юк ки,
Син - чиксез шәфкатьле,
чиксез мәрхәмәтле».
(«Хәшер» сүрәсенең
10 нчы аяте).

Мәгълүматны
дини чыганаклардан
**Шамил БАҺАУТДИН**
туплады.